| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 3 апреле Олы Ачасыр авылы № 7

Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2020 елның 17 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2021 елның 01 мартындагы 8 номерлы үзгәрешләр кертелгән)

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр исемлеген актуальләштерүгә бәйле рәвештә Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 17 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган (2021 елның 01 мартындагы 8 номерлы үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген түбәндәге эчтәлектәге 7 пункты белән тулыландырырга:

- бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт

(җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл
жирлеге башлыгы И.М. Саттаров